**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 26 ноябрендәге 4129 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 29 октябрендәге 2828 номерлы**
**«Казан шәһәренең яшелләндерү объектларын, кече архитектура формаларын, тукталыш павильоннарын һәм куркынычсызлык коймаларын карап тоту эшләренә финанс чыгымнары нормативлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәренең яшелләндерү объектларын, кече архитектура формаларын, тукталыш павильоннарын һәм куркынычсызлык коймаларын норматив буенча карап тотуны тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 29 октябрендәге 2828 номерлы «Казан шәһәренең яшелләндерү объектларын, кече архитектура формаларын, тукталыш павильоннарын һәм куркынычсызлык коймаларын карап тоту эшләренә финанс чыгымнары нормативлары турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләренә (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәренең яшелләндерү объектларын, кече архитектура формаларын, тукталыш павильоннарын, куркынычсызлык коймаларын, пюпитрларны, җәяүлеләр өчен мәгълүмат күрсәткечләрен һәм Казан шәһәренең мәгълүмат карталарын норматив буенча карап тотуның тәэмин ителешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга»;

1.2. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.3. әлеге kararга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 29 октябрендәге 2828 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 29 сентябрендәге 3334 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 29 октябрендәге 2828 номерлы “Казан шәһәренең яшелләндерү объектларын, кече архитектура формаларын, тукталыш павильоннарын һәм куркынычсызлык коймаларын карап тоту эшләренә финанс чыгымнары нормативлары турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.В.Куляжевка йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын**
**башкаручы – урынбасар** **И.В.Куляжев**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 26 ноябрендәге
4129 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәренең яшелләндерү объектларын, кече архитектура формаларын, тукталыш павильоннарын һәм куркынычсызлык киртәләрен карап тоту эшләренә финанс чыгымнары нормативлары**

| **Атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Тариф, сумнарда** |
|---|---|---|
| Бакча-парклардагы урналарны карап тоту | | |
| Урналарны су сиптереп юу машинасы шлангы ярдәмендә юу | Урна | 25,70 |
| Урналар өслеген кул белән юу | Урна | 32,15 |
| Урналарны чүптән чистарту | Урна | 14,38 |
| Газоннарны карап тоту | | |
| Яткан карны газон буйлап тарату | Кв.м | 19,76 |
| Коелган яфраклар күләме уртача булган очракта, яфракларны җыештыру (тырмалап җыю) | Кв.м | 28,06 |
| Коелган яфраклар күләме күп булган очракта, яфракларны җыештыру (тырмалап җыю) | Кв.м | 42,34 |
| Туфракка коры минераль ашламалар кертү | Кв.м | 56,69 |
| Чүп үләннәрен агулы химикатлар белән юк итү | Кв.м | 3,05 |
| Очраклы чүпне җыю һәм чыгару | Кв.м | 0,06 |
| Газоннарны моторлы чапкыч белән чабу | Кв.м | 5,03 |
| Газоннарны чапкычлы трактор белән чабу | Кв.м | 0,31 |
| Газон чәчү | Кв.м | 52,07 |
| Газоннарга су сиптереп юу машинасы шлангы ярдәмендә су сибү | Кв.м | 11,29 |
| Газоннарны утау | Кв.м | 10,22 |
| Бакча-парклардагы диваннарны карап тоту | | |

| **Атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Тариф, сумнарда** |
|---|---|---|
| Диваннар өслеген юу | Кв.м | 44,05 |
| Диваннардагы, эскәмияләрдәге карны себерке белән чистарту һәм читкә ыргыту | Кв.м | 29,59 |
| Бакча-парклардагы диваннарны су сиптереп юу машинасы шлангы ярдәмендә юу | Кв.м | 5,64 |
| Һәйкәлләрне, пюпитрларны, пьедесталларны, барельефларны, фигураларны, җәяүлеләр өчен мәгълүмат күрсәткечләрен һәм Казан шәһәренең мәгълүмат карталарын карап тоту | | |
| Җәйге чорда пьедесталлардагы һәм барельефлардагы, фигуралардагы тапларны һәм пычракны җылы су белән юу, корытып сөртү | Кв.м | 16,94 |
| Фигураларны һәм барельефларны таплардан, корымнан һәм башка пычрактан вышкалар ярдәмендә махсус җентекләп чистарту | Кв.м | 176,70 |
| Кышкы чорда фигураларны һәм барельефларны вышкалар ярдәмендә кардан чистарту | Кв.м | 54,47 |
| Пьедесталларны һәм барельефларны, фигураларны, бәстән һәм пычрактан арындырып һәм сөртеп, кардан чистарту | Кв.м | 29,59 |
| Чәчәк түтәлләрен карап тоту | | |
| Чәчәк түтәлләрендәге карны тарату | Кв.м | 19,76 |
| Чәчәк түтәлләрен чәчәкле үсемлекләрнең шиңгән сабакларыннан арындыру, аларны түтәлдән читкә чыгару | Кв.м | 17,50 |
| Коры минераль ашламалар кертү | Кв.м | 57,90 |
| Яшел үсентеләргә су сиптереп юу машинасы шлангы ярдәмендә су сибү | Кв.м | 11,29 |
| Чәчәк түтәлләрен утау | Кв.м | 50,82 |
| Баскычларны карап тоту | | |
| Баскычларның төшә торган урыннарын пычрактан һәм чүптән чистарту | Кв.м | 7,03 |
| Баскычларны су сиптереп юу машинасы шлангы ярдәмендә су басымы астында юу | Кв.м | 11,29 |
| Баскычларның төшә торган урыннарын, тыгызланып каткан карны ватып, кардан һәм боздан чистарту | Кв.м | 41,80 |
| Баскычларның төшә торган урыннарына кул белән бозлавыкка каршы материаллар сибү (материал бәясе белән) | Кв.м | 3,04 |
| Плитәләр араларында үскән чүп үләннәрен агулы химикатлар ярдәмендә юк итү | М | 3,05 |
| Җәйге чорында чүп үләннәрен бетерү | М | 6,14 |

| Атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тариф, сумнарда |
|---|---|---|
| Агачларны карап тоту | | |
| Агач кәүсәсе тирәли урнаштырыла торган рәшәткәне алып, агач төпләрен казу һәм йомшарту, рәшәткәне урнаштыру | Данә | 279,50 |
| Агач кәүсәсендәге үсентеләрне кисү | Агач | 50,92 |
| Агач төбеннән үсеп чыккан үсентеләрне кисү | Кв.м | 38,36 |
| 5 метрдан биегрәк агачларның ябалдашларын форма биреп кисү | Агач | 10 236,24 |
| 5 метрга кадәр биеклектәге агачларның ябалдашларын форма биреп кисү | Агач | 2 223,60 |
| Агач ябалдашларын автогидрокүтәргеч ярдәмендә санитар кисү | Агач | 1 293,92 |
| Агачларны санитар кисү | Агач | 885,95 |
| Диаметры 32 сантиметрга кадәр булган агач төпләрен казып чыгару | Агач | 117,18 |
| Диаметры 32 сантиметрдан артык булган агач төпләрен казып чыгару | Агач | 196,30 |
| Агач төпләрен утау һәм йомшарту | Агач | 62,51 |
| Туфракка коры минераль ашламалар кертү | Кв.м | 57,90 |
| Су сибү өчен агач төпләрен казу һәм канаулар ясау | Кв.м | 89,66 |
| Агачларга агулы химикатлар сибү | Агач | 131,35 |
| Агачларга су сиптереп юу машинасы шлангы ярдәмендә су сибү | Агач | 282,29 |
| Кәүсә диаметры 50 сантиметрга кадәр булган агачларның төп ян ботакларын яшәртү өчен кисү | Агач | 9 751,52 |
| Кәүсә диаметры 50 сантиметрдан артык булган агачларның төп ян ботакларын яшәртү өчен кисү | Агач | 11 354,66 |
| Диаметры 0,5 метрга кадәр булган каты яфраклы агачларны автогидрокүтәргеч ярдәмендә аудару | Агач | 10 431,24 |
| Диаметры 0,5 метрдан артык булган каты яфраклы агачларны автогидрокүтәргеч ярдәмендә аудару | Агач | 21 275,38 |
| Диаметры 0,5 метрга кадәр булган йомшак яфраклы һәм ылыслы агачларны | Агач | 8 499,22 |

| Атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тариф, сумнарда |
|---|---|---|
| автогидрокүтәргеч ярдәмендә аудару | | |
| Диаметры 0,5 метрдан артык булган йомшак яфраклы һәм ылыслы агачларны автогидрокүтәргеч ярдәмендә аудару | Агач | 18 599,09 |
| Кәүсә диаметры 16 сантиметрга кадәр булган агачларны аудару (автогидрокүтәргечсез) | Агач | 5 319,11 |
| Кәүсә диаметры 24 сантиметрга кадәр булган агачларны аудару (автогидрокүтәргечсез) | Агач | 6 440,68 |
| Кәүсә диаметры 36 сантиметрга кадәр булган агачларны аудару (автогидрокүтәргечсез) | Агач | 10 253,86 |
| Кәүсә диаметры 36 сантиметрдан артык булган агачларны аудару (автогидрокүтәргечсез) | Агач | 13 858,82 |
| Куаклыкларны карап тоту | | |
| Вак яфраклы, каты яфраклы куаклардан торган киртәләрне кырку | М | 38,58 |
| Куаклыкларның төпләрен утау һәм йомшарту | Куак | 10,00 |
| Үсемлекләрдән торган киртә төпләрен утау һәм йомшарту | Үсемлекләрдән торган 1 м киртә | 18,74 |
| Су сибү өчен ялгыз үскән куакларның төпләрен казу һәм канаулар ясау | Куак | 14,35 |
| Су сибү өчен үсемлекләрдән торган киртә сыйфатында утыртылган куакларның төпләрен казу һәм канаулар ясау | Үсемлекләрдән торган 1 м киртә | 20,82 |
| Диаметры 1 метрга кадәр булган, ялгыз үскән яфраклы куакларны кисү һәм сирәкләү | Куак | 46,16 |
| Диаметры 1 метрдан артык булган, ялгыз үскән яфраклы куакларны кисү һәм сирәкләү | Куак | 76,82 |
| Куаклыклар өчен туфракка коры минераль ашламалар кертү | Куак | 9,28 |
| Үсемлекләрдән торган киртә өчен туфракка коры минераль ашламалар кертү | Үсемлекләрдән торган 1 м киртә | 17,36 |
| Куаклыкларга агулы химикатлар сибү | Куак | 25,54 |
| Үсемлекләрдән торган киртәгә агулы химикатлар сибү | Үсемлекләрдән торган 1 м киртә | 20,23 |
| Куакларга су сиптереп юу машинасы шлангы ярдәмендә су сибү | Куак | 7,06 |
| Үсемлекләрдән торган киртәгә су сиптереп юу машинасы шлангы ярдәмендә су сибү | Үсемлекләрдән | 14,10 |

| Атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тариф, сумнарда |
|---|---|---|
| | торган 1 м киртә | |
| Су акваторияләрен карап тоту | | |
| Очраклы чүпне җыю | Кв.м | 0,06 |
| Су өслегенн чүптән чистарту | Кв.м | 25,30 |
| Тышкы коймаларны, терәк стеналарны, юл киртәләрен һәм тавыштан саклагыч экраннарны карап тоту | | |
| Коймаларны су сиптереп юу машинасы шлангы ярдәмендә тузаннан һәм пычрактан су белән чистарту | М | 22,58 |
| Коймаларны кардан һәм пычрактан чистарту | М | 5,05 |
| Катнаш төрдәге юл машиналары җайланмаларын (ян-якка урнаштырыла торган щетка) кулланып, коймаларны кардан һәм пычрактан чистарту | М | 0,52 |
| Терәк стеналарны һәм тавыштан саклагыч экраннарны юу | Кв.м | 11,29 |
| Тукталыш павильоннарын, пюпитрларны, җәяүлеләр өчен мәгълүмат күрсәткечләрен һәм Казан шәһәренең мәгълүмат карталарын карап тоту | | |
| Павильон стеналарын чистарту һәм юу | Кв.м | 33,88 |
| Павильон өслеген юу | Кв.м | 44,05 |
| Стена өслекләрен игъланнардан, рөхсәт ителмәгән рекламадан кул белән чистарту | Кв.м | 144,86 |
| Өслекләрне граффитидан чистарту | Кв.м | 2 718,65 |
| Автопавильоннарны һәм алар янәшәсендәге территорияләрне чүптән, кардан һәм боздан чистарту | Кв.м | 32,28 |
| Тукталыш павильоны түбәсеннән кар төшерү | Кв.м | 22,63 |
| Күрсәткечләрне, перголаларны юу | Кв.м | 11,29 |
| Күрсәткечләрне сөртү | Кв.м | 44,05 |
| Юлларны һәм балалар, спорт мәйданчыкларын карап тоту | | |
| Юлларны кышкы чорда карап тоту | Кв.м | 1,01 |

| **Атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Тариф, сумнарда** |
|---|---|---|
| Юлларны җәйге чорда карап тоту | Кв.м | 0,43 |
| Балалар, спорт мәйданчыкларын кышкы чорда карап тоту | Кв.м | 6,00 |
| Балалар, спорт мәйданчыкларын җәйге чорда карап тоту | Кв.м | 3,00 |
| Чүп үләннәрен агулы химикатлар белән юк итү | Кв.м | 3,05 |
| Җәйге чорда бортиклар буйлап үскән чүп үләннәрен бетерү | М | 6,14 |
| Йөк ташу, төяү | | |
| Йөкләрне 5 километрга кадәр булган ераклыкка ташу | Тонна | 130,32 |
| Йөкләрне 10 километрга кадәр булган ераклыкка ташу | Тонна | 212,93 |
| Йөкләрне 15 километрга кадәр булган ераклыкка ташу | Тонна | 240,46 |
| Туфракның үсемлек үстерү өчен яраклы катламын (җир, черемә) төяү | Тонна | 99,34 |
| Кәс төяү | Тонна | 298,02 |
| Утын, агач калдыкларын, агач кисүдән барлыкка килгән калдыкларны һ.б. төяү | Тонна | 419,84 |
| Чүп төяү | Тонна | 82,21 |

_______________